**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮТАЗЫ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**423962, Ютазы авылы,**
**Дмитров урамы, 2**
**тел. 4-00-91**
**факс: 8 (85593) 4-00-93**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЮТАЗИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**423962 с. Ютаза,**
**ул. Дмитрова, д.2**
**тел. 4-00-91**
**факс: 8 (85593) 4-00-93**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 2**

**КАРАР**
**«31» гыйнвар 2023 ел**

2023 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм күмү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, 2022 елның 27 гыйнварындагы «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 57 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында"гы 196 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р  и т т е:

1. 2023 елның 1 февраленнән Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлегендә күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен әлеге карарның 1 нче кушымтасы һәм 2 нче кушымтасы нигезендә 7793,48 (җиде мең җиде йөз туксан өч сум 48 тиен) суммасында билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 28 гыйнварындагы «2022 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында»гы 6 санлы карарын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Бердәм

порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ютазы авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы: Н.Ф.Җәләев

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Ютазы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның 31 гыйнварындагы
2 санлы карарына
1 кушымта

2023 елның 1 февраленнән күмү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумга) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне бирү һәм җибәрү | 3115,52 |
| 3. Ziратка үлгән кешенең мәетен (калдыкларын) алып бару | 952,3 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3725,66 |
| Барлыгы | 7793,48 |

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
Районы Ютазы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның 31 гыйнварындагы
2 санлы карарына
2 кушымта

2023 елның 1 фераленнән күмү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 723,02 |
| 3. Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне бирү һәм җибәрү | 2392,5 |
| 4. Ziратка үлгән кешенең мәетен (калдыкларын) алып бару | 952,3 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3725,66 |
| Барлыгы | 7793,48 |